РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

02 июнь 2023 ел №174

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлегенең
генераль планын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2010 елның 25 декабрендәге № 98-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә, 2023 елның 10 апрелендәге № 1 җәмәгать фикер алышулары үткәрү нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең генераль планы (2015 ел редакциясендә) кушымтага ярашлы рәвештә;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү (2023 ел редакциясендә), кушымтага ярашлы рәвештә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертүне раслау турында» 2023 елның 27 апрелендәге № 176 карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының

рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

Чирмешән муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов